КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 1 октябрь г.Казань № 885

2019/2020 уку елында гражданнарны хәрби исәптәге белгечлекләр буенча әзерләү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе гражданнарын хәрби хезмәткә әзерләү турындагы нигезләмәне раслау хакында» 1999 ел, 31 декабрь, 1441 нче карары нигезендә һәм гражданнарны хәрби исәптәге белгечлекләр буенча хәрби хезмәткә әзерләүне камилләштерү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

2019/2020 уку елында Татарстан Республикасында гражданнарны хәрби исәптәге белгечлекләр буенча әзерләү буенча төп чаралар планын;

2019/2020 уку елына «Татарстан Республикасының Армиягә, авиациягә һәм флотка булышлык күрсәтү буенча ирекле оешмасы (ДОСААФ)» төбәк иҗтимагый-дәүләт берләшмәсенең һәм «Россия Федерациясенең Армиягә, авиациягә һәм флотка булышлык күрсәтү буенча ирекле оешмасына (ДОСААФ) караган Татарстан Республикасы Үзәк аэроклубы» коммерциягә карамаган автоном өстәмә һөнәри белем бирү оешмасының (алга таба – Россия Федерациясенең Армиягә, авиациягә һәм флотка булышлык күрсәтү буенча ирекле оешмасына (ДОСААФ) караган Татарстан Республикасы Үзәк аэроклубы) гражданнарны хәрби исәптәге белгечлекләр буенча әзерләүне гамәлгә ашыручы белем бирү оешмаларында гражданнарны хәрби исәптәге белгечлекләр буенча әзерләү йөкләмәсен (алга таба – йөкләмә);

2019/2020 уку елына «Татарстан Республикасының Армиягә, авиациягә һәм флотка булышлык күрсәтү буенча ирекле оешмасы (ДОСААФ)» төбәк иҗтимагый-дәүләт берләшмәсенең һәм Россия Федерациясенең Армиягә, авиациягә һәм флотка булышлык күрсәтү буенча ирекле оешмасына (ДОСААФ) караган Татарстан Республикасы Үзәк аэроклубының гражданнарны хәрби исәптәге белгечлекләр

буенча әзерләүне гамәлгә ашыручы белем бирү оешмаларында гражданнарны хәрби исәптәге белгечлекләр буенча әзерләүнең барышын тикшерүдә тоту планын;

2019/2020 уку елында «Татарстан Республикасының Армиягә, авиациягә һәм флотка булышлык күрсәтү буенча ирекле оешмасы (ДОСААФ)» төбәк иҗтимагый-дәүләт берләшмәсенең һәм Россия Федерациясенең Армиягә, авиациягә һәм флотка булышлык күрсәтү буенча ирекле оешмасына (ДОСААФ) караган Татарстан Республикасы Үзәк аэроклубының гражданнарны хәрби исәптәге белгечлекләр буенча әзерләүне гамәлгә ашыручы белем бирү оешмаларында гражданнарны хәрби исәптәге белгечлекләр буенча әзерләү вакытларын.

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына эшсез дип билгеләнгән тәртиптә танылган эшләмәүче хәрби хезмәткә чакырылучылар арасындагы гражданнарны хәрби исәптәге белгечлекләр буенча әзерләүне оештырырга.

3. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына, Татарстан Республикасының һөнәри белем бирү оешмалары җитәкчеләренә сәламәтлекләренең торышы буенча яраклы һәм 2020 елда хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле булган гражданнарны сайлап алу һәм «Татарстан Республикасының Армиягә, авиациягә һәм флотка булышлык күрсәтү буенча ирекле оешмасы (ДОСААФ)» төбәк иҗтимагый-дәүләт берләшмәсенең һәм Россия Федерациясенең Армиягә, авиациягә һәм флотка булышлык күрсәтү буенча ирекле оешмасына (ДОСААФ) караган Татарстан Республикасы Үзәк аэроклубының белем бирү оешмаларына хәрби исәптәге белгечлекләр буенча укырга җибәрү эшен оештырырга, шулай ук Татарстан Республикасы Хәрби комиссариатына әлеге эшне оештыруны тәкъдим итәргә.

4. «Татарстан Республикасының Армиягә, авиациягә һәм флотка булышлык күрсәтү буенча ирекле оешмасы (ДОСААФ)» төбәк иҗтимагый-дәүләт берләшмәсенең Россия Федерациясенең Армиягә, авиациягә һәм флотка булышлык күрсәтү буенча ирекле оешмасы (ДОСААФ) белән төзелгән 2019 елда гражданнарны хәрби исәптәге белгечлекләр буенча әзерләү өчен федераль бюджеттан субсидияләр бирү турындагы килешүе нигезендә, Татарстан Республикасы Хәрби комиссариатына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

«Татарстан Республикасының Армиягә, авиациягә һәм флотка булышлык күрсәтү буенча ирекле оешмасы (ДОСААФ)» төбәк иҗтимагый-дәүләт берләшмәсенең һәм Россия Федерациясенең Армиягә, авиациягә һәм флотка булышлык күрсәтү буенча ирекле оешмасына (ДОСААФ) караган Татарстан Республикасы Үзәк аэроклубының гражданнарны хәрби исәптәге белгечлекләр буенча әзерләүне гамәлгә ашыручы белем бирү оешмаларына Россия Федерациясе Оборона министрлыгы йөкләмәсе нигезендә хәрби исәптәге белгечлекләр буенча әзерләү өчен гражданнарны сайлап алуны һәм әлеге оешмаларны алар белән комплектлауны тәэмин итүне;

«Татарстан Республикасының Армиягә, авиациягә һәм флотка булышлык күрсәтү буенча ирекле оешмасы (ДОСААФ)» төбәк иҗтимагый-дәүләт берләшмәсенең һәм Россия Федерациясенең Армиягә, авиациягә һәм флотка булышлык күрсәтү буенча ирекле оешмасына (ДОСААФ) караган Татарстан Республикасы Үзәк аэроклубының гражданнарны хәрби исәптәге белгечлекләр

буенча әзерләүне гамәлгә ашыручы белем бирү оешмаларын һөнәри белем бирү оешмаларының чыгарылыш курс укучылары (студентлары) белән комплектлауның исәп-хисабын әзерләүне;

«Татарстан Республикасының Армиягә, авиациягә һәм флотка булышлык күрсәтү буенча ирекле оешмасы (ДОСААФ)» төбәк иҗтимагый-дәүләт берләшмәсе, Россия Федерациясенең Армиягә, авиациягә һәм флотка булышлык күрсәтү буенча ирекле оешмасына (ДОСААФ) караган Татарстан Республикасы Үзәк аэроклубы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасының һөнәри белем бирү оешмалары белән берлектә, гражданнарны хәрби исәптәге белгечлекләр буенча әзерләүне 2018 елның 1 октябреннән, һөнәри белем бирү оешмалары мөмкинлегеннән чыгып, ике (өч) агымда үткәрүне;

«Татарстан Республикасының Армиягә, авиациягә һәм флотка булышлык күрсәтү буенча ирекле оешмасы (ДОСААФ)» төбәк иҗтимагый-дәүләт берләшмәсе белән берлектә, «Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында» 1998 ел, 28 март, ФЗ-53 нче Федераль законны тормышка ашыруга бәйле рәвештә, гражданнарны хәрби исәптәге белгечлекләр буенча әзерләүне финанслауны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында» Федераль законны тормышка ашыруга бәйле рәвештә, Россия Федерациясе оешмалары һәм гражданнары тоткан чыгымнарны компенсацияләү тәртибе хакында» 2004 ел, 1 декабрь, 704 нче карары нигезендә башкаруны.

5. Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына, Татарстан Республикасы Хәрби комиссариатына һәм «Татарстан Республикасының Армиягә, авиациягә һәм флотка булышлык күрсәтү буенча ирекле оешмасы (ДОСААФ)» төбәк иҗтимагый-дәүләт берләшмәсенә эчке эшләр органнарында исәптә торучы гражданнарны Татарстан Республикасының хәрби хезмәткә чакырганга кадәр әзерләү үзәкләрендә әзерләүне оештыруны тәкъдим итәргә.

6. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына, «Татарстан Республикасының Армиягә, авиациягә һәм флотка булышлык күрсәтү буенча ирекле оешмасы (ДОСААФ)» төбәк иҗтимагый-дәүләт берләшмәсенә, Россия Федерациясенең Армиягә, авиациягә һәм флотка булышлык күрсәтү буенча ирекле оешмасына (ДОСААФ) караган Татарстан Республикасы Үзәк аэроклубына, Татарстан Республикасының урта һөнәри белем бирү оешмалары җитәкчеләренә, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белән берлектә, түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

2019/2020 уку елында Россия Федерациясе Кораллы Көчләре өчен белгечләр әзерләүне бу карар белән расланган йөкләмә нигезендә «Татарстан Республикасының Армиягә, авиациягә һәм флотка булышлык күрсәтү буенча ирекле оешмасы (ДОСААФ)» төбәк иҗтимагый-дәүләт берләшмәсенең һәм Россия Федерациясенең Армиягә, авиациягә һәм флотка булышлык күрсәтү буенча ирекле оешмасына (ДОСААФ) караган Татарстан Республикасы Үзәк аэроклубының гражданнарны хәрби исәптәге белгечлекләр буенча әзерләүне гамәлгә ашыручы белем бирү оешмаларында тәэмин итүне;

«Татарстан Республикасының Армиягә, авиациягә һәм флотка булышлык күрсәтү буенча ирекле оешмасы (ДОСААФ)» төбәк иҗтимагый-дәүләт берләшмәсенең гражданнарны хәрби исәптәге белгечлекләр буенча әзерләүне

гамәлгә ашыручы белем бирү оешмаларында гражданнарны хәрби исәптәге белгечлекләр буенча әзерләүне йөкләмә нигезендә һөнәри белем бирү оешмаларында белем алучы гражданнар арасындагы затларны – кичке вакытта яки дәрестән тыш вакытта – уку процессыннан аермыйча; эшләүче гражданнарны – җитештерүдән аермыйча; эшләми һәм укымый торган гражданнарны көндез яки кичке вакытта оештыруны.

7. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2018/2019 уку елында гражданнарны хәрби исәптәге белгечлекләр буенча әзерләү турында» 2018 ел, 22 сентябрь, 834 нче карары үз көчен югалткан дип санарга.

8. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Премьер-министрының беренче урынбасары, Татарстан Республикасы хәрби хезмәткә чакыру комиссиясенең резерв составы рәисе Р.К.Нигъмәтуллинга йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин